**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

# КАРАР

№ 75 18.11.2016ел.

«Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы территориясендә җирләрдән файдалануга муниципаль җир контроле турында»2014 елның 18 декабрендәге 245 номерлы Аксубай муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясенең 25.10.2001 елгы 136-ФЗ номерлы Җир кодексына ярашлы рәвештә Аксубай муниципаль районы Советы:

1. Аксубай муниципаль районы Советының 18.12.2014 ел, № 245 карары белән расланган Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы территориясендә җирләрдән файдалануга муниципаль җир контроле турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә: :

1.1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы территориясендә җирдән файдалануга муниципаль җир контроле турында нигезләмәнең 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«4. Муниципаль җир контроле Аксубай муниципаль районы территориясендә гамәлгә ашырыла:

- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Аксубай шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитеты (алга таба - муниципаль җир контроле органы) «Аксубай шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чикләрендә урнашкан җир мөнәсәбәтләре объектларына карата;

- Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты (алга таба - муниципаль җир контроле органы), Аксубай муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы (алга таба - муниципаль җир контроле органы) Аксубай муниципаль районы торак пунктлары арасында урнашкан җир мөнәсәбәтләре объектларына, шулай ук Аксубай муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләре чикләрендә урнашкан җир мөнәсәбәтләре объектларына карата.»

2.Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://aksubayevo.tatarstan.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай муниципаль районы Советының агросәнәгать комплексы, җирдән файдалану һәм экология мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Аксубай муниципаль районы башлыгы,
Совет Рәисе К. К. Гилманов